РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ БОЛЬШЕНЫРСИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ТЮЛЯЧИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА**

ул.Школьная, 10, село Большие Нырси, 422094, Тел.: (884360)53-1-25(факс)
E-mail: Bnrs.Tul@tatar.ru

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

**ТЕЛӘЧЕ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ОЛЫ НЫРСЫ АВЫЛЫ ҖИРЛЕГЕ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**

Мәктәп урамы, 10 Олы Нырсы авылы, 422094 Тел.: (884360)53-1-25(факс)
E-mail: Bnrs.Tul@tatar.ru

ОКПО 94318116 ОГРН 1061675010847 ИНН/КПП 1619004450/161901001

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ**
**№2**

**КАРАР**
**«31» гыйнварь 2020 г.**

2020 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Нырсы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «күмү һәм күмү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон,«2020 елда түләүләрне, пособиеләрне һәм компенсацияләрне индексацияләү коэффициентын раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 29 январь 2020 елның 61 номерлы карары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 15 статьясындагы 3 өлешенең 15 пункты нигезендә, Теләче муниципаль районы Олы Нырсы авыл җирлеге Башкарма комитеты,

## КАРАР БИРӘ:

1. 2020 елның 1 февраль көненнән алып Теләче муниципаль районының Олы Нырсы авыл җирлегендә, 1 нче кушымта һәм 2 нче кушымта, гарантияләнгән җирләү хезмәтләре исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын 6124,86 сум күлмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карар гамәлдәге законнар нигезендә үз көченә керә.
3. «Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Нырсы авыл җирлегендә җирләү буенча хезмәтләр күрсәтүнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр хакын раслау турында» 2019 елның 14 март №10 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Р.М.Гиниятов

Теләче муниципаль районы Башкарма комитеты карарына
1 номерлы кушымта
«31» гыйнварь 2020 ел №2

**2020 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Нырсы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум.)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2.Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү | 2500 |
| 3. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең җәсәден зиратка ташу, ритуаль билгеләнештәге әйберләр китерү) | 844,86 |
| 4. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2780 |
| **Барлыгы** | 6124,86 |

Теләче муниципаль районы Башкарма
комитеты карарына
2 номерлы кушымта
«31» гыйнварь 2020 ел №2

**2020 елга Татарстан Республикасы Теләче муниципаль районының Олы Нырсы авыл җирлегендә җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлеге бәясе**

| Хезмәт күрсәтү атамасы | Хезмәт күрсәтү бәясе *(сум.)* |
|---|---|
| 1. Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2.Тәнне кәфенләү | 1300 |
| 3.Ритуаль билгеләнештәге предметларны бирү | 1200 |
| 4. Транспорт хезмәтләре күрсәтү (мәрхүмнең җәсәден зиратка ташу, ритуаль билгеләнештәге әйберләр китерү) | 844,86 |
| 5. Җирләү (каберләрне казу һәм күмү) | 2780 |
| **Барлыгы** | 6124,86 |